“Туган ягым – яшел бишек” төбәкара фәнни-гамәли укытучылар конференциясен үткәрү турында нигезләмә

1. Гомуми мәгълүмат

Әлеге нигезләмә “Туган ягым – яшел бишек” төбәкара фәнни-гамәли конференциясен үткәрүнең максатын, бурычларын билгели; конференцияне оештыру, үткәрү, йомгаклау, җиңүчеләрне бүләкләү тәртибе белән таныштыра.

2. Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Конференциянең максаты – укытучыларның төрле фәннәр буенча эзләнү эшчәнлеге аша иҗади фикер йөртүләрен, интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру.

2.2. Төп бурычлары:

- белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү, тәҗрибә уртаклашу;
- югары уку йортларында һәм матбугат чараларында эшләүче галимнәрне, белгечләрне, мөхәррирләрне, язучыларны укытучылар белән эшчәнлеккә тарту.

3.Бәйгене оештыручылар

- Казан федераль университеты Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәге
- “ТАТМЕДИА” ААҖ “Чын мирас” журналы редакциясе
- Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе

4. **Катнашучылар**

Конференциядә татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучылары, мәктәп музейлары һәм китапханәләре хезмәткәрләре, туган төбәкне өйрәнүчеләр катнаша ала.

5. **Конференция кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:**

1. **Төбәк тарихы** (үзегез яшәгән район, шәһәр, авылларның тарихы яки төбәктә булган тарихи вакыйгалар). **Җитәкчеләр: Ленар Гобәйдуллин 89520365448**
2. **Шәхесләребез – туган як горурлыгы** (үз төбәгегездән чыккан күренекле мәгърифәтчеләр, язучы, шагыйрьләр һ.б. күренекле шәхесләрнең тормыш юлларына бәйле истәлекләр, аларның фәнни-иҗади эшчәнлекләре). **Җитәкче: Ләбиб Лерон 8(843)222-09-83 (17-91)**
3. **Сәнгать** (төбәктәге декоратив-гамәли сәнгать: тегү-чигү, каюлы күн, зәркән, агачны кисеп бизәк ясау һ.б. осталарының иҗаты, фотоларда – тарих: тарихи шәхесләрне, борынгы милли киемнәрне, кыр эшләре барышын, тарихи биналарны, һөнәрчелекне тасвирлаган һәм **үзегез тарихи яктан кызыклы дип санаган иске фоторәсемнәр)**. Җитәкче: **Данил Салихов**
4. **Әдәбият дәресләрендә –туган төбәк** (дәресләрдә туган җиргә, шәхесләренә мәхәббәт тәрбияләү, төбәктән чыккан әдип һәм шагыйрьләрнең иҗатын укыту методикасы, аларның иҗаты белән тәрбия чараларын оештыру). **Җитәкчеләр: Сиринә Трофимова 89093088105, Алия Мөбәрәкшина 89872240915**

6. **Конференциядә катнашу тәртибе**

6.1. Конференциядә укытучылар, мәктәп музейлары һәм китапханәләре хезмәткәрләре, төбәкне өйрәнүчеләр фәнни-эзләнү эшләре белән катнаша.

6.2. **Конференция ике этапта үтә:**

- 2014 елның 19 мартына кадәр конференция читтән торып үтә – килгән эшләр тикшерелә.
- Икенче этапка узган укытучылар 2014 елның 26 мартта 8.00 сәгатькә Актаныш авылына фәнни-гамәли конференциясенең финалына чакырыла. Алар секцияләрдә